| ГЛАВА БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БИЛӘР АВЫЛ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12. 2019 с. Билярск № 28

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Шама авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе нигезендә

**карар кылам:**

1. 2019 елның 21 декабрендә 11:00 сәгатьтә Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлегенең Шама авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 1 Төркем инвалидлардан, көндезге укудагы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнардан, 4 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү;
- торак пунктларда урамнарны яктырту;
- күмелгән урыннарны карап тоту һәм төзекләндерү;
- техниканы карап тоту (трактор, килешү буенча хезмәт хакы);
- контейнер мәйданчыклары төзү;
- торак пунктлардагы агач коймаларны төзекләндерү (капиталь ремонтлау)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

4. Җыенны үткәрү урыны итеп Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Шама авылы, Елга аръягы урамы, 17 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасын билгеләргә кирәк

5. Әлеге карарны Биләр авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Шама авылы, Елга аръягы урамы, 17 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында; Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Шама авылы, Колхоз урамы, 30 нчы йорт адресы буенча мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы** **Г.Г.Хәбибуллин**

СОВЕТ БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ